ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октября 2024 ел № 287

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегендә су белән тәэмин итү һәм су агызу объектларына карата концессия килешүе төзү турында карар кабул итү хакында" 23.10.2024 елның 281 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына, салкын су белән тәэмин итүгә һәм (яисә) су бүлеп чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концеденты булып тора торган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган мондый системаларның аерым объектларына карата концессион килешүләр әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 16 февралендәге 132 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегендә су белән тәэмин итү һәм су агызу объектларына карата концессия килешүе төзү турында карар кабул итү хакында" 23.10.2024 елның 281 номерлы карарына Түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Карар):

1.1. Карардан 7 пунктны төшереп калдырырга.

1.2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге су белән тәэмин итү һәм су агызу объектларына карата концессия килешүе төзү хокукына конкурс документациясе» 4 номерлы кушымтасын карардан төшереп калдырырга.

1.3. Карардан 7 пунктны төшереп калдыруга бәйле рәвештә, карарның 8,9,10 пунктларын тиешенчә 7,8,9 пунктлары итеп укырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.А. Поносовка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**